ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк, 19

СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алан-Бексер , ул. Центральная, д. 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51 e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**2020 елның 13 октябре**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 12**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 декабрендәге 100 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибе”нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1. өлеш белән тулыландырырга:

«1.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«инициатив проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башлыгы — З.Р.Гарифуллина